ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**23.10.2020**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 2062**

«Зеленодольск шәһәрендә торак урыны мәйданының исәпкә алу нормасын һәм торак урын бирү нормасын билгеләү турында» Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 25 сентябрендәге 1830 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Торак урын мәйданының исәпкә алу нормасын һәм Зеленодольск шәһәрендә торак урын бирү нормасын билгеләү турында» 2020 елның 25 сентябрендәге 1830 номерлы карарында җибәрелгән техник хатаны төзәтү максатларында, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Торак урын мәйданының исәпкә алу нормасын һәм Зеленодольск шәһәрендә торак урын бирү нормасын билгеләү турында» 2020 елның 25 сентябрендәге 1830 номерлы карарының 1 пунктына, «18» санын «12» санына алмаштырып, үзгәреш кертергә.
2. Әлеге карарны Зеленодольск муниципаль районы Советының җәмәгатьчелек һәм ММЧ белән элемтә бүлеге начальнигына массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга, Интернет челтәрендәге Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.
3. Карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче вазыйфасын башкаручы А.В. Старостин